Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

# Ислам Нуры

№ 19 (647) 12 октябрь, 2017 ел (1439, Мөхәррәм) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+

## БЕЗГӘ КОРОЛЬ КИЛДЕ



4 октябрьдә Согуд Гарәбстаны Короле Сәлман бен Габдел Азиз Әл Сауд Мәскәүгә дәүләт визиты белән килде. Кремльдә Россия Президенты Владимир Путинның Король белән очрашуы узды. 7 октябрьдә Согуд Гарәбстаны короле Россия мөселманнарының рухи лидерлары белән очрашты. Очрашу тар составта монархның Россиягә визиты кысаларында Согуд Гарәбстаны инициативасы белән узды. Катнашучылар арасында баш мөфти, Россиянең Үзәк мөселманнар Диния нәзарәте рәисе, шәйх Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Карачай-Черкесия Республикасы мөфтие Исмәгыйль Бердиев, Дагыстан мөфтие Әхмәд хәзрәт Абдуллаев, Чечня мөфтие Сәлах Межиев, Ингушетия республикасының дин мәсьәләләре буенча киңәшчесе Магомед хаҗи Албогачиев, Төньяк Кавказ мөселманнары Координацион үзәгенең Мәскәүдәге генераль вәкиле Шәфигъ Пшихачев, РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Рушан хәзрәт Аббясов, Россия мөселманнары Дини җыены мөфтие Әлбир Крганов, шулай ук ике дәүләт илчеләре: Габдрахман бен Ибраһим әр-Расси һәм Сергей Козлов бар иде. Очрашу барышында Король экстремизм белән көрәштә, бар дөньяда куркынычсызлык һәм иминлеккә ирешүдә төрле дин-мәдәният вәкилләре арасында диалог һәм хезмәттәшлекнең югары әһәмиятен ассызыклады. Үз ягыннан Тәлгать хәзрәт Россиядә ислам диненең барлыкка килү һәм үсеше тарихы, Болгар академиясе ачылышы турында сөйләде, Россиядә 7,5 мең мәчет эшләве турында әйтте.

**ТР МДН сайтыннан.**

## Мөгаллимнәр киңәш тотты



3 октябрьдә “Ак мәчет”тә Чаллы мәчетләре якшәмбе укытучыларының шәһәркүләм киңәшмәсе булды. Анда шәһәр имамнары да катнашты. Шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, төбәк казые Рөстәм хәзрәт Шәйхевәли, Чаллы мөхтәсибәтенең уку-укыту бүлеге мөдире Илназ хәзрәт Яхин, шәһәрнең Җәмигъ мәчете мөгаллимәсе Равия ханым Зиярова якшәмбе укуларын нәтиҗәлерәк итү буенча үз фикерләрен җиткерделәр. Якшәмбе укуларын алып барырга фәкать аттестацияне уңышлы үткән мөгаллим-мөгаллимәләр генә хокуклы. Аттестация үтәргә өлгермәгән яңа мөгаллимнәр укыту эшенә Диния нәзарәтендә аттестация узгач кына тотыначак.

Киңәшмәдә яңа хаҗ сезонына әзерләнү буенча да сүз булды. Бу мәсьәлә буенча “ДУМ РТ ХАДЖ” менеджеры Айдар Бикмөхәммәтов чыгыш ясады һәм сорауларга җаваплар бирде.



Укытучыларга Чаллы “Хәләл-Үзәге” бүләге — уку әсбаплары таратылды. Алар мәчетләрдәге беренче уку елын башлаучыларга да бүләк итеп биреләчәк.

## Ислам – мәрхәмәтлелек дине

Чаллы шәһәренең “Тәүбә” мәчетендә яшьләр өчен түгәрәк өстәл булып узды. “Тәүбә” мәчете имам-хатыйбы Әбүбәкер хәзрәт Абдеев, “Ихлас” мәчете имамы Илназ хәзрәт Яхин һәм Түбән Кама имам-мөхтәсибе Сәлимҗан хәзрәт Ибраһимов үз чыгышларында хәнәфи мәзһәбе фикъһенә кагылышлы сораулар белән таныштырдылар, ислам диненең мәрхәмәтлелек дине булуы турында сөйләделәр.



## Яңа мәчет



Күптән түгел генә ачылган Элемтә авылы мәчетендә Мөслим районы имам-хатыйбларының чираттагы укулары оештырылды. Әлеге мәчетне шушы авыл егете, 17 яшендә китеп, гомер буе Себерякларында хезмәт куйган Минһаҗетдинов Әскать Хаҗи улы үз хисабына һәм балалары ярдәме белән төзеткән. Имам-хатыйблар Мөслим районы имам-мөхтәсибе Әбделкәрим хәзрәт дәресен, Расих хәзрәт чыгышын тыңладылар, “Түгәрәк өстәл”дә фикер алыштылар.

## Хәйриягә кушылып



Өлкәннәр декадасына багышлап, Чаллының “Әбүзәр” мәчетендә дә ел саен хәйрия чаралары үтә. “Быел да мәчеткә йөрүче өлкәннәргә күчтәнәчләр тапшырдык, - ди мәчетнең имам-хатыйбы Али хәзрәт Баһаветдинов. — Олы кешеләрнең әздән дә күңеле була, иң мөһиме — аларны онытмау, кешелекле мөнәсәбәттә булу”.

## Дәвамлы гамәлләр



Чаллы мөхтәсибәте каршындагы “Ихсан” Хәйрия фонды Корбан гаете чорында 343 кг корбан ите җыйган иде. Ул шушы көннәрдә мохтаҗларга, авыруларга тулысынча таратып бетерелде. Хәйрия пакетларын таратуны “Ихлас”, “Сөембикә”, Әбүзәр” һәм “ГЭС” мәчете әһелләре башкарды. Мөхтәсибәт каршындагы “Хәзинә” балалар клубына да корбан ите тапшырылды.

* * *

Чаллыда игелек чаралары дәвам итә. 29 нчы гимназиядә 650 кеше өчен корбан ашы үткәрелде. Мондый гамәлләр яшь буынны тәрбияләүдә матур бер үрнәк булып тора.



# Картлык һәркемгә килә

**Илебез буенча октябрь ае башында үнкөнлек Өлкәннәр көне дип игълан ителә. Төрле җирләрдә өлкәннәрне котлаулар, бүләкләүләр, искә алулар бара.**

Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең бер хәдисе бар: «Аллаһ Тәгалә каршысында әти-әнинең догасы, мосафирның һәм мазлум кешенең догасы кабул булмый калмас». Өлкәннәр — барысы да диярлек әти-әниләр. Алар — догасы кабул була торган төркемгә керәләр. Мазлум ул — кайсы яктан да булса кимсетелгән, кыерсытылган, рәнҗетелгән, ниндидер кайгы-хәсрәт кичергән кеше, дигән сүз. Бүгенге өлкәннәр нәкъ шундыйлар. Хәзерге 60-70 яшьлек кешеләрнең ямьле, шатлыклы балачагы булганмы? Аларның балачагын сугыш тартып алган, матур балачаклары булмаган бит. Ачлык-ялангачлык. Бүгенге нәниләр күргән балачакны күргәнме алар? Күрмәгән. Сугышка кадәр күргәннәре — ачлык, 21 нче, 30 нче еллар. Шуннан килеп — сугыш. Сугыштан соңгы хәерчелек. Әле Аллаһның рәхмәте белән, кулы эш белгән, сәламәт кешеләргә 15-20 ел акча эшләргә мөмкинлек булган. Инде анысын да сыпырып алып, юкка чыгардылар. Кемдер мая туплаган булса, хөкүмәт анысын тагын җыештырып алды. Менә шулай караганда, бу өлкән буын бөтен яктан кимсетелгән булып чыга.

Ә бүгенге өлкәннәрнең иң кызганыч ягы шул — алар гомер буе диннән мәхрүм ителеп яшәделәр. Дингә каршы тәрбия алган, диннән читләштерелгән буын бу. Картаймыш көнендә намаз укып, шуннан ләззәт таба алмаган буын. Аллаһка гыйбадәт кылудан үзенә тынычлык таба алмаган кеше — ул бик мескен бәндә. Монысына да җәмгыятьнең гаебе бик зур. Туганнан алып, 70 ел буе дин тискәре яктан гына аңлатылган икән, дингә каршы сөйләнгән икән, аны бер-ике елда гына үзгәртеп корып булмый. Бу киртәне атлап чыгуы бик авыр. Бәхетле кеше шулдыр ки: кем дә кем Аллаһ Тәгаләгә һәм ахирәт көненә ышана. Бәхетсез кеше — үлдең дә беттең, дип уйлаган адәм. Үлгәннән соң терелүгә бүген күп кеше ышанмый. Менә шуңа өлкәннәребезнең кайберләре өметсезлектә яши. Өметле кеше Аллаһка, ахирәт көненә ышана намазын укый, уразасын тота, садәкасын бирә, изге гамәлләр кыла, җәннәтле булам, дип яши . Бүген, Аллаһка шөкер, мәчетләр бар. Әле кайчан гына, картларга җыелып утырырга урын таба алмый интегә идек. Әлхәмдулилләәәһ, мәчетләр булды, килергә, гыйлем алырга, дин юлына керергә мөмкин. Бүген хөкүмәткә рәхмәттән башка нәрсә әйтәсең. Гыйбадәт кылырга бөтен мөмкинек тудырылган. Күңелдәге күп еллар буе җыелып килгән караңгылыкны юарга кирәк: үзеңне-үзең җиңеп, шушы гыйбадәт йортына килергә. Ә инде яшьләргә, шушыларны аңлап, әти-әниләребезне кичерергә туры килә. Без алар белән матур иттереп яши белергә тиешбез. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: «Кем кеше алдында анасын йә атасын сүксә, йә зарланса, ул кеше бездән түгел, ул мөселман булмас», —диде. Әти-әни — ул безнең тәкъдиребез. Әти-әнине без сайлап ала алмыйбыз. Туган җирне дә, милләтебезне дә сайлап ала алмыйбыз. Шушы милләт кешесе булып, шушы авылда, шушы әти-әнидән дөньяга туганбыз икән, без әти-әнигә, шушы туган җиребезгә, милләтебезгә хезмәт итәргә тиешбез. Әти-әни начар була алмый, аларның балага карата кылган гамәлендә рия юк. Без бик күп җирдә эшлибез, күп кешеләргә булышабыз, бер-беребезгә бүләкләр бирешәбез, бер-беребезне бәйрәмнәр белән котлашабыз, әмма моның һәрберсендә әзме-күпме рия бар. Кеше берәүгә кулалмашка эшкә бара икән, бу да миңа булышыр әле, ди. Берәүгә бүләк бирә икән, ул миңа нindине бирер икән, ди. Әз генә булса да шундый уй килә башка. Эшен яхшы үтәсә, моның өчен мине мактарлар, сөйләрләрме икән, дип көтә. Әти-әни исә баласына яхшылык эшли икән, фәкать баласына яхшы булсын өчен генә эшли. Шуңа күрә әти-әни догасы мәртәбәле, чөнки аның кылган гамәлендә рия (икейөзлелек) юк. “Изге ният белән эшләнгән гөнаһлы эштә дә гөнаһ юк”, ди дин галиме Муса Бигиев. Чөнки әти-әни бары изге ният белән генә эшли. Без шуны дөрес аңламыйча, зарланышып, ачуланышып йөрсәк, икеләтә гөнаһлы булабыз. Чөнки без әти-әниләребезнең саф хисләрен аяк астына салып таптыйбыз.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткән: «Үзенең бу дөньяда ни эшләгәнен күрмичә берәү дә дөньядан үтмәс». Димәк, без өлкән кешеләрне, әти-әниләребезне урынсызга рәнҗетәбез икән, каһәрлибез икән, картаймыш көнебездә, үзебез әти-әни булгач, шушыны ук күрәчәкбез. Инде кадерләп, хөрмәтләп озатабыз икән әти-әниебезне, картаймыш көнебездә Аллаһның рәхмәте белән, бәлки, безгә дә Хак Тәгаләнең һидәяте булыр. Безне дә балаларыбыз хөрмәтләр. Бер риваять бар. Берәүнең әтисенең кулы калтырый башлый. Ашаганда, кул калтырагач, ашы-чәе түгелгән. Килен әйтә: “Бу атаң каршында мин ашый алмыйм, әтиеңне читкә күчереп утырт”, — ди. Улы атасын күчереп утырта. Бераздан килен: “Ул икенче бүлмәдә утырсын. Үзең ашат, минем аны күрәсем килми. Бөтен нәрсәне түгеп, чәчеп бетерә”, —ди. Картны икенче бүлмәгә чыгаралар. Тагын күпмедер вакыт үткәч, килен: “Син атаңны урамга куып чыгар, югыйсә, мин синең белән тормыйм”, — ди. Улы, җәймә биреп, әтисен урамга куып чыгарырга әзерләнә. Шулвакыт аның янына кечкенә малае килә дә: «Әти, бабайның ярты җәймәсен алып кал, мин сине куып чыгарганда, үзеңә кирәк булыр», — ди. Менә бу риваять — Пәйгамбәрнең хәдисенә дәлил. Кеше үзе кылганны күрмичә дөньядан үтмәс.

Муса галәйһиссәләм белән Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм —Аллаһ белән турыдан-туры сөйләшкән кешеләр. Бүтән пәйгамбәрләр Аллаһ белән турыдан-туры сөйләшә алмаганнар. Муса галәйһиссәләм Аллаһ Тәгалә белән сөйләшкәндә Аллаһтан сораган: «Син мине бик мәртәбәле дәрәҗәгә күтәрдең, инде җәннәттә урыным кем белән булыр икән, күрсәт әле?» Аллаһ Тәгалә әйтә: “Фәлән шәһәргә бар, фәлән җиргә кер”, — ди. Керсә, анда бер ит чабучыны күрә. Муса галәйһиссәләмнең җәннәттә урыны бергә булачак кеше ит чабучы булып эшли икән. Күрешә, мин сиңа кунакка килгән идем, ди. Теге кеше эшен куя, өенә алып кайта Муса галәйһиссәләмне. Аның Пәйгамбәр икәнен белми. Өенә кереп утыртып куя да, үзе, түр якка кереп, күпмедер вакыт югалып тора. Муса галәйһиссәләм сорау бирә: «Мосафирны калдырып китәрлек нинди эшең бар иде синең?» — ди. «Минем, — ди, — түр як өйдә авыру әнием ята. Мин аның хәлен белдем, асларын алыштырдым, ашаттым. Инде менә хәзер мосафирны кунак итәргә чыктым», — ди ит чабучы. «Анаң берәр сүз әйтмәдеме?» — ди Муса. Теге кеше әйтә: “Әнием дога кылды, җәннәттә урының Муса галәйһиссәләм белән янәшә булсын иде, дип Аллаһтан сорады”, — ди. Менә әнинең догасы нинди көчкә ия!

Тагын бер риваять. Берәү җан бирә алмыйча ята икән. Сәхабәләр килә, беренче азан әйтүче Билал (р.г.) да килә. Гомәр (р.г.) дә килә. Теге: «Ләәә иләәһә илләллааәһ», — дип әйтә алмый, җан бирә алмый, шәһадәтлек кәлимәсен дә әйтә алмый. Ята шулай урын өстендә. Сорашалар. Намаз да укыган, ураза да тоткан, сәдаканы да бик күп биргән кеше икән үзе. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтә: «Әти-әнисе бармы?» — ди. Әтисе үлгән, әнисе бар, диләр. «Минем янга килерлек микән әнисе? Килерлек булмаса, үзем барам», — ди. Әнисенә кеше җибәрә. Теге хатын, минем килүем әҗерлерәк булыр, ди. Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.) янына килә. Килгәч, сорый Пәйгамбәребез: «Берәр үпкәң бар идеме әллә малаеңа?» — ди. «Бераз үпкәм бар иде, — ди әнисе. — Әле дә кичерә алмыйм. Һәрвакыт минекен түгел, хатынының сүзен өстен чыгарды. Хаклымы-хаксызмы, шуңа үпкәләгән идем», — ди. «Менә малаең, — ди Пәйгамбәр, — хәзер шәһадәт кәлимәсен дә әйтә алмый, җан бирә алмыйча азапланып ята, имансыз китүе бар. Кичер малаеңны», — ди. Шуннан Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм күп итеп утын өйдертеп, ут төртә дә: «Син карап тор, малаеңны хәзер утка аталар», —ди. Теге хатын әйтә: «Утка атмагыз, мин чыдый алмыйм», — ди. Пәйгамбәребез әйтә: «Менә син аны, ризасызлыгың белән, мәңгелек утка хөкем иттең. Үзең 2-3 сәгать утта януын да күтәрә алмыйсың», — ди. «Ярар, алайса бәхиллегемне бирәм», — ди анасы. Шул вакытта малае да: «Ләәә иләәһә илләллааәһ Мүхәммәдүр Рәсүүлүллааәһ», дип, җан бирә. Иман белән китә. Әти-әнинең бәхиллеген алалмасак, безнең дә имансыз китүебез бик мөмкин.

Коръәндә Аллаһ Тәгалә: “Башта Аллаһ Тәгаләгә итагать итегез, аннан Аллаһның Рәсүленә итагать итегез, сайлап куйган җитәкчеләрегезгә, әти-әниләрегезгә итагать итегез”, — ди. Әти-әни дигәне инде ул — өлкән буын кешеләр, һәм, әлбәттә, әти-әниләр, әби-бабайлар да үзләрен итагатьле итеп тотсалар, күркәм була. Аллаһ Тәгалә безгә намаз укуны боерды. Телегез зикердә булсын, диде. Мине искә алыгыз, намаз укыгыз, гыйбадәт кылыгыз, диде. Әмма безнең бүген олыларыбызның кайбере теләсә нәрсә сөйләп, гайбәт сатып көн уткәрә. Бу да ярый торган эш түгел, бу хәл олыларны бизәми. Һәрнәрсәне бизи торган сыйфат бар, олыларны бизи торган сыйфат — гыйбадәт. Менә без бабайларыбызның авырган вакытта да ничек итеп намазга йөргәннәрен искә алабыз. Мәчет юк иде ул вакытта, тәравихка дип, төрле кешеләргә йөриләр иде. Сарайларда гает укыйлар иде. Хәзер күркәм мәчетләр була торып, шуңа да йөрмәүче картлар бар. Аракы эчеп, тәмәке тартып, урамда яшьләр белән бәхәсләшеп, әшәкеләнеп йөриләр. Хәлнең бу ягын да истән чыгармаска кирәк. Өлкәннәр көне икән, өлкәннәр дип, сезне чакыралар икән, берәр җиргә барасыз икән, үзегезне өлкәннәрчә тотарга кирәк, яшьләргә үрнәк булырга тиешсез. Өлкәннәрнең артында 60-70 еллык тормыш тәҗрибәсе бар. Дөньяның төрле хәлен күргәнсез, һәрнәрсәгә аек, дөрес бәя бирә аласыз, әлхәмдүлилләәәһ, үзегезнең булган белемегезне, тәҗрибәгезне яшьләргә биреп, алар белән матур иттереп яшәргә кирәк. Балаларга Аллаһны, дөньяны танырга өйрәтеп, һөнәрләр биреп, оныкларыгызга да үрнәк булыгыз. Оныкларыбыз үзебезгә дога кылучылар булсыннар иде. Безгә шулай итеп яшәргә кирәк. Өлкәннәр яшәрә алмаса да, Ходай гомер бирсә, бар яшь кеше дә картаячак. Җитәкчеме, баймы, ярлымы, матурмы ул, Аллаһ Тәгалә гомер бирә икән, барыбызга да картлык киләчәк. Шуны һич онытырга ярамый. Картайгач, безне дә хөрмәт итсеннәр дисәк, без үзебез Пәйгамбәребезнең хәдисенә муафыйк булып, бүген әти-әни, әби-бабаларыбызны, өлкәннәрне хөрмәт итеп, аларны рәхәткә тиендереп, аларның догасын алып калырлык итеп яшәргә тиешбез.

Дөрес яшәүнең нәтиҗәсе, мәгънәсе шул. Озак яшәүдә генә дә түгел, гомерең, тәкъдирең буенча, кайчан тәгәлләнсә, шул вакытта синең эшләгән изгелегең явызлыгыңнан күбрәк булырга тиеш. Сиңа дога кылып, бәхиллеген биреп, кешеләр синнән риза булып калсыннар. Шулай булганда, Аллаһ Тәгалә: «Ләәә иләәһә илләллааәһ Мүхәммәдүр Расүүлүллааәһ», дип иман белән үтү бәхетен бирә. Шуның аркылы без җәннәткә ирешербез. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең бер хәдисе бар: «Яхшы тәрбия белән тиңләшә ала торган бернинди байлык та юк», — диде. Гомер үтә, кеше картая, балалар үстерә. Бер көн килә, гомер буе туплаган байлыгын биреп, бер күркәм холыклы бала кирәксенә, шуның белән тынычлап картлык кичерер идем, дип өзгәләнә. Әмма эшли алмый. Балаларга калдырырга яхшы тәрбиядән дә зуррак байлык юк.

Менә шушыны истә тотып, өлкәннәр киләчәк буынны тәрбияләүче кешеләр булырга тиеш. Һәм, без эшләгән ялгышларны сез дә кабатлый күрмәгез дип, балаларыгызга аңлатырга кирәк. Аллаһтан да шуны сорарга кирәк. Аллаһны зикер итәргә кирәк, намазларга йөрергә. Шәт, Аллаһ Раббыбыз барыбызга да иман байлыгы бирер.

*Дөнья әдәбияты җәүһәрләреннән*

# Йөрәк бабай һәм падишаһ

*(Хикәят. Төрекчәдән Фатих Кутлу тәрҗемәсе. Дәвамы)*

ҖАҺИТ ЗАРИФОГЛУ

Ярар, Йөрәк бабайның, дөяне күргәч, күңеле җылынган. Хәтта йөрәге әрнегән. Аңа шуның өчен дә Йөрәк Хасан дигәннәр бит. Шундый мәрхәмәтле, шундый сөйкемле була ул.

Якынрак килеп, күзен дөядән алмыйча гына, сорап куйган:

— Бу сөйкемле, җанга якын дөякәйнең хакы күпме?

— Бер яхшы сүзгә бирәем сезгә, - дип җавап биргән хуҗасы.

“Бу нинди сүз?” - дип әйтергә дә өлгермәгән, хуҗасы дөянең бавын Йөрәк бабайның кулына тоттырып, китеп тә барган.

— Тукта, - дип Йөрәк бабай аны тиз генә куып җиткән дә, кулыннан эләктереп алган. — Кара әле, иптәш, ни эшләвең бу? Мин бит ничә сум гына дип сорадым. Нинди гаеп эшләдем, кулыма бавын тоттырып качасың?

— Бабай, - дигән, - әйттем ләбаса хакын: бер сөю дә бер яхшы сүз, дип.

— Ярар, - дигән Йөрәк Хасан. — Алла бирсә, рәнҗетмәбез аны, яхшы карарбыз. Тик әйт әле: бирәчәгем күпме, икенчедән, акчам җитәрлекме, юкмы?

— Җитәрлек, җитәрлек!

— Алайса, әйт, күпме?

— Бабай! Бер сөю белән бер яхшы сүз, - дигән сатучы яңадан.

— Улым, күреп торасың: яшем шактый, тезләремнең җегәре дә юк, уйнап юанма минем белән.

— Нинди уйнап юану булсын. Алай бик түлисең килсә, ярар алайса. Ярар да... Һымм...

Йөрәк бабай да кызыксынып көтә. Ниһаять:

— Иң яхшысы: син моны миннән бүләк итеп кабул ит. Иншаллаһ, файдасын күрерсең, - дигән.

— Алай булмый. Минем акчам бар бит, - дигән Йөрәк бабай.

— Күпме акчаң бар?

— Менә! - дигән һәм бер бакыр акча чыгарып күрсәткән.

— Ооо! — дигән хуҗа. — бу бик күп була бит. Сиңа бу акчага ике дөя бирерләр.

— Әллә миннән көләсең инде син? Бу акчага кечкенә генә бер ишәк тиясен син дә яхшы беләсең. Хәтта тимәс тә әле...

— Алай! Димәк, шәһәрдә бәяләр бик арткан. Белми дә йөрим икән. Ярый алайса, бир бакыр акчаңны, ал дөяне.

Кул кысыша башлыйлар. Бер-берсенең кулларын тоткан килеш селкепме селкиләр. Берсе, алдым, ди, берсе, бирдем, ди: “Һәммәсе белсен, белмәгән калмасын! Һәркем шаһит булсын! Дөя өчен мин бер акча бирдем. Мин дә дөя өчен бер бакыр акча алдым”.

Шул рәвешле, дөянең бавыннан тотып, Йөрәк бабай өенә юнәлгән. Хуҗа исә, бакыр акчаны кулында әвәли-әвәли, башка бер якка юл тоткан.

Әйберләрне дөягә төягән чакта, аны базардан ничек сатып алганын тагын бер мәртәбә исенә төшергән Йөрәк бабай. Дөя бик тә яшь, буе да тәбәнәк икән. Ләкин аяклары, муены, күкрәк итләре тулышып тора икән. Тамагы бик нык ачкан кеше аңа карап алса, авызыннан сулар килерлек.

Йөрәк бабай хатынына:

— Җанкисәгем, шушы дөя булмаса, быел җәйләүгә дә күченә алмас идек, - дигән.

— Әйе шул. Аның хакын ничекләр генә үтәп бетерербез икән?

Шулай итеп, капкаларын бикләп, өйләрен Аллага тапшырып, тауларга таба юл тотканнар.

Бара-бара кичкә таба җәйләүнең беренче тукталышына килеп җиткәннәр. Әгәр дә берәр каршылык килеп чыкмаса, икенче көнне башка тукталышка, өченче көнне җәйләүгә җитәчәкләр икән.

Йөрәк бабай белән хатыны, дөягә төягән йөкне бушатып, тиз генә йон чатырны корганнар. Җиде урынга җиде казык какканнар. Чатырның җепләрен бәйләгәннәр. Җилфер-җилфер җил исә икән. Түбәндә, моннан еракта, бер шәһәрнең җем-җем янган утлары күзгә күренә. Тау бөҗәкләренең исләре бер-берсенә шулкадәр кушылган ки, иснәгән кеше исерер, һуштан язар.

— Әй Раббым, - диде Йөрәк бабай. — Тауларың үзгә, сәһилләрең үзгәчә. Кояшны чыгарасың, караңгылыкны китерәсең. Күкне йолдызларың белән бизисең. Дөнья шул тауларның авырлыгын күтәрә дә, бер бәндә бер гөнаһ эшләгәч, күкләр тетрәнә. Синең газабың үткәнче, фәрештәләр куркуларыннан үләләр. Әй, бөек Раббым, Син яралткан меңнәрчә бөҗәк хакы өчен, яралткан меңләгән ис хакы өчен мине ярлыка, мине гамәлләремә карап бәяләмә, мең ел гомер бирсәң, мең ел синнән башкасын уйламыйча гыйбадәт кылсам да, биргән бер бөртек күз нуры белән карап, галәмне күрүнең хакын, шөкерен үти алмам. Син мине кичермәсәң, мин нишләрмен? Син беркемгә дә мохтаҗ түгел, әмма без һәрберебез сиңа мохтаҗбыз. Синең ярдәмеңнән башка нәрсә эшләр идек?

Айшә әби гел Йөрәк бабайның артында утырып, аның сөйләгәннәрен йотлыгып тыңлап, онытылып китә. Вакыт-вакыт тетрәнеп кайнар күз яшьләрен түгә.

Тора-бара икесен дә йокы үз ястыкларына чакырып, атынгычына утыртып атындырган. Икесе дә фәрештәләрнең канатлары астында, еракларга сузылган төшләренең атынчыкларында, учактагы ялкынны тукландырып яшәткән яңа һава кебек, йокыга талганнар. Тау һавасы салкынча да, җанлы да. Билгеле, бик тә арган булалар.

Дөя чатырның алдында гына тора. Ашказаны да яңа ашалган үләннәр белән тулы. Җиргә яткан да башын түбәндәге шәһәрнең җем-җем янып сүнгән утларына борган. Аннан ниндидер хәбәр, яки хәбәр китерүчене, яисә берәр кунакны көткән төсле керфек какмыйча ята. Тик бу күзләр гүя бер төш күрәләр шикелле. Юешләнеп ялтырыйлар.

Иртәсен таң атмас борын тордылар. Янә шундый ук җанлылык, шундый ук тизлек белән күз кабакларын ачтылар. Акыл тәндәге урынын алу белән, авыздан чыккан беренче сүз, башка килгән беренче җөмлә дә: әшһәдү ән ләәә иләәһә илләллааһ вә әшһәдү әннә Мүхәммәдәр расүллуллаһ...

Янә су, янә комган. Янә тәһарәт, янә намаз. Яңа урында өстәлгән дәрт белән бер мәртәбә кыйблага юнәлтелгән тирән дикъкать була аларда. Хәзер зиһен үзгәрәк. Караш җанлырак. Намаз тагын да иркен. Йөрәк бабай шулай, Аллаһу әкбәр, диюгә Айшә әби җил бәргән сыман тирбәлеп китә. Дөя иңри. Барча бөҗәкләр берьюлы тыналар.

Шәһәрнең утлары карала, әмма аның урынына башка бер яктылык төшә башлый.

Сәлам, сәлам, сәлам, сәлам, сәлам... (иминлек, тынычлык). Уңга... галәмнең теге башына кадәр тарала. Сәлам, сәлам, сәлам, сәлам, сәлам...

***(Дәвамы бар)***

## ӘДӘБИ СҮЗ

### Картлар йорты

Керфекләрен ачты кояш,
Сөеп кенә җиргә бакты.
Кайгы да юк, хәсрәт тә юк —
Дөнья нурлы, дөнья якты.

Гел аклыктан тора дөнья,
Әллә шулай тоеламы?
Ак кояштан нурлар түгел,
Күз яшьләре коеламы?

Тәрәз аша баккан берәү,
Кояшны да күрми кебек.
Төсе уңган күзләрендә
Яшәү суты беткән кибеп.

Көннәр үтә, төннәр үтә,
Тәрәзәдән кояш китә.
Арык кулы каш өстендә,
Сукыр ана кемне көтә?

Бары да бар бу йортында:
Яктысы да, җылысы да.
Ни кирәк дип, йөгереп йөри
Кечесе дә, олысы да.

Табыны мул өстәлендә,
Сөйләшергә күршесе бар.
Тик юатмый берни җанны —
Аның көткән кешесе бар.

Талчыбыктай иде буе,
Янәшәдә кызы, улы.
Гөрләп торган гаиләсенең
Күптән инде сүнгән уты.

Пар канаты сынып төште,
Таралышты балалар да.
Хәсрәтләрен учка кысып,
Ялгыз калды газиз ана.

Ташламады мал-туарын,
Егәр барда дөнья көтте.
Нигез ташка кайтыр әле
Балалар дип гомер итте.

Кайтмадылар, югалдылар,
Анда-санда хат салдылар.
Кайтып килеп хәл белергә
Һич тә вакыт тапмадылар.

Көннәр үтте, төннәр үтте,
Көтә-көтә күзләр бетте.
Ялгыз калган чал ананы
Картлар йорты гына көтте.

Бары да бар бу йортында:
Яктысы да, җылысы да.
Ни кирәк дип, йөгереп йөри
Кечесе дә, олысы да.

“Өлкәннәрнең көне” диеп
Килгән була олы-кече.
Бүләге мул, сүзе татлы,
Тик ул түгел көткән кеше.

Картлар йорты,
                бары да бар.
Тик көткәннәр байлык түгел.
“Игелек”тән сыкрап елый,
Сынык күңел, китек күңел.

Кайда ялгыш? Нигә болай?
Йөрәк түре — тоташ яра.
Картлар йорты тәрәзендә
Өмет булып кояш яна.

**Сөмбел Хәбибуллина,**
**Актаныш районы**
**Әтәс авылы укытучысы.**

## САУЛЫГЫМ – БАЙЛЫГЫМ

***Каюм Насыйри***

### Күзгә “дарулар”

Һәркем үз җиренең һавасына, табигатенә ияләшкәнлектән, үз җирендә үскән үсемлек аның табигатенә яраклы булып, сырхавына да үз җиренең дару үләннәре килешәрәк төшә. Кеше катнашыннан башка, үзеннән-үзе кырларда, сахраларда һәм урманнарда үскән үлән кеше хезмәте белән бакчаларда тәрбия кылып үстергән үләннәрдән кулайрак һәм сырхаулар өчен дә файдалырак.

Күз күнендә берьеллык үләннең тамырын җыю кирәк. Күзен аны яфраклары тәмам коелып беткәч җыйсалар, яз башында үлән яфрак һәм күпшә чыгармас борын җыярга була. Тамырны яхшылап чистартып, туфракларын сөртеп бетерергә кирәк. Әмма тамыр хуш исле булса, су белән юу мәслихәт түгел, чөнки югач, тамырның дару үзлеге кими. Әгәр юан, сулы тамыр булса, буйга телеп һәм җепкә тезеп, күләгә җирдә киптерергә, бик озак кибә торган тамыр булса, мичтә киптерергә дә мөмкин. Керән, аир тамыры шикеллеләрне, киптермичә, базда саклау мәслихәт.

Үләннәрдән тыш, бакчадагы җиләк-җимешләр, яшелчәләр дә дәвалау үзлегенә ия.

***Әрекмән.*** Аның тамырын буйга телеп киптерергә була. Бу тамыр тирләтә, бәвелне куа һәм бәвел юлын саф кыла. Орлыгы эчне йомшартыр. Тигәнәк орлыгыннан кызгылт төсле май алалар, башка сөртсәң, бик файдалы. Баш авыртканда, яфрагын да кат-кат итеп ябу файда бирер. Чуаннарга, сызлавыкларга һәм башка җәрәхәтләргә япсаң да файдасы күп.

***Алма*** — күзге бакчаның бизәге. Ул җиңелчә бизгәккә, ашказаны шешкәнгә һәм эчәгеләр пешеккәнгә бик файдалы. Алманың суын сыгып, лимон белән катнаштырып эчсәң, температураны төшерер.

***Балан*** — салкынлык бирүче һәм бөрештергеч. Күкрәк авыруларына файдасы бар. Согы тән чабырганга бик файдалы.

***Кабак***ның орлыгы һәм орлыгының мае эчтәге тасма суалчаннарны һәм кортларны куа. Сусыз пешкән кабак баш миенә һәм йөрәккә куәт бирә, арка суын арттыра, йомшаклык бирә.

# Намаз вакытлары

| Милади Ноябрь | Көн исеме | Сәфәр, Рабигуль-әүвәл | Иртәнге намаз | | | Кояш чыга | | | Өйлә | | | Икенде | | | Ахшам | | | Ястү | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан |
| 1 | Чш | 12 | 06.14 | 04.29 | 04.42 | 08.17 | 06.35 | 06.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.48 | 13.58 | 14.11 | 17.40 | 15.51 | 16.04 | 19.21 | 17.36 | 17.49 |
| 2 | Пж | 13 | 06.16 | 04.31 | 04.44 | 08.19 | 06.37 | 06.50 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.46 | 13.56 | 14.09 | 17.38 | 15.49 | 16.02 | 19.20 | 17.34 | 17.47 |
| 3 | Жм | 14 | 06.18 | 04.33 | 04.46 | 08.21 | 06.39 | 06.52 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.44 | 13.55 | 14.07 | 17.36 | 15.47 | 16.00 | 19.18 | 17.32 | 17.45 |
| 4 | Шм | 15 | 06.20 | 04.34 | 04.48 | 08.23 | 06.41 | 06.54 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.42 | 13.53 | 14.06 | 17.34 | 15.45 | 15.58 | 19.16 | 17.30 | 17.43 |
| 5 | Як | 16 | 06.21 | 04.36 | 04.49 | 08.25 | 06.43 | 06.56 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.40 | 13.51 | 14.04 | 17.32 | 15.43 | 15.56 | 19.14 | 17.28 | 17.41 |
| 6 | Дш | 17 | 06.23 | 04.38 | 04.51 | 08.27 | 06.45 | 06.59 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.38 | 13.49 | 14.02 | 17.30 | 15.41 | 15.54 | 19.13 | 17.27 | 17.40 |
| 7 | Сш | 18 | 06.25 | 04.40 | 04.53 | 08.29 | 06.47 | 07.01 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.37 | 13.47 | 14.00 | 17.28 | 15.39 | 15.52 | 19.11 | 17.25 | 17.38 |
| 8 | Чш | 19 | 06.27 | 04.42 | 04.55 | 08.31 | 06.49 | 07.03 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.35 | 13.45 | 13.58 | 17.26 | 15.37 | 15.50 | 19.10 | 17.23 | 17.36 |
| 9 | Пж | 20 | 06.28 | 04.43 | 04.56 | 08.33 | 06.51 | 07.05 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.33 | 13.43 | 13.56 | 17.24 | 15.35 | 15.48 | 19.08 | 17.22 | 17.35 |
| 10 | Жм | 21 | 06.30 | 04.45 | 04.58 | 08.35 | 06.54 | 07.07 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.32 | 13.42 | 13.55 | 17.22 | 15.33 | 15.46 | 19.07 | 17.20 | 17.33 |
| 11 | Шм | 22 | 06.32 | 04.47 | 05.00 | 08.37 | 06.56 | 07.09 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.30 | 13.40 | 13.53 | 17.21 | 15.31 | 15.44 | 19.05 | 17.19 | 17.32 |
| 12 | Як | 23 | 06.33 | 04.48 | 05.02 | 08.39 | 06.58 | 07.11 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.28 | 13.38 | 13.51 | 17.19 | 15.30 | 15.42 | 19.04 | 17.17 | 17.30 |
| 13 | Дш | 24 | 06.35 | 04.50 | 05.03 | 08.41 | 07.00 | 07.13 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.27 | 13.37 | 13.50 | 17.18 | 15.28 | 15.41 | 19.02 | 17.16 | 17.28 |
| 14 | Сш | 25 | 06.36 | 04.52 | 05.05 | 08.43 | 07.02 | 07.15 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.25 | 13.35 | 13.48 | 17.15 | 15.26 | 15.39 | 19.01 | 17.14 | 17.27 |
| 15 | Чш | 26 | 06.38 | 04.53 | 05.07 | 08.45 | 07.04 | 07.17 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.24 | 13.34 | 13.46 | 17.14 | 15.24 | 15.37 | 19.00 | 17.13 | 17.26 |
| 16 | Пж | 27 | 06.40 | 04.55 | 05.08 | 08.47 | 07.06 | 07.19 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.22 | 13.32 | 13.45 | 17.12 | 15.23 | 15.35 | 18.58 | 17.12 | 17.25 |
| 17 | Жм | 28 | 06.41 | 04.57 | 05.10 | 08.49 | 07.08 | 07.21 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.21 | 13.31 | 13.43 | 17.11 | 15.21 | 15.34 | 18.57 | 17.10 | 17.23 |
| 18 | Шм | 29 | 06.43 | 04.58 | 05.12 | 08.51 | 07.10 | 07.23 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.19 | 13.29 | 13.42 | 17.09 | 15.19 | 15.32 | 18.56 | 17.09 | 17.22 |
| 19 | Як | 30 | 06.44 | 05.00 | 05.13 | 08.53 | 07.12 | 07.25 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.18 | 13.28 | 13.41 | 17.08 | 15.18 | 15.31 | 18.55 | 17.08 | 17.21 |
| 20 | Дш | 1 | 06.46 | 05.02 | 05.15 | 08.55 | 07.14 | 07.27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.17 | 13.26 | 13.39 | 17.06 | 15.16 | 15.29 | 18.54 | 17.07 | 17.20 |
| 21 | Сш | 2 | 06.47 | 05.03 | 05.16 | 08.57 | 07.16 | 07.29 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.16 | 13.25 | 13.38 | 17.05 | 15.15 | 15.28 | 18.53 | 17.06 | 17.19 |
| 22 | Чш | 3 | 06.49 | 05.05 | 05.18 | 08.59 | 07.18 | 07.31 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.14 | 13.24 | 13.37 | 17.03 | 15.13 | 15.26 | 18.52 | 17.05 | 17.18 |
| 23 | Пж | 4 | 06.50 | 05.06 | 05.19 | 09.00 | 07.20 | 07.33 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.13 | 13.23 | 13.35 | 17.02 | 15.12 | 15.25 | 18.51 | 17.04 | 17.17 |
| 24 | Жм | 5 | 06.52 | 05.08 | 05.21 | 09.02 | 07.22 | 07.35 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.12 | 13.21 | 13.34 | 17.01 | 15.11 | 15.24 | 18.50 | 17.03 | 17.16 |
| 25 | Шм | 6 | 06.53 | 05.09 | 05.22 | 09.04 | 07.24 | 07.37 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.11 | 13.20 | 13.33 | 17.00 | 15.09 | 15.22 | 18.49 | 17.02 | 17.15 |
| 26 | Як | 7 | 06.55 | 05.11 | 05.24 | 09.06 | 07.25 | 07.39 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.10 | 13.19 | 13.32 | 16.59 | 15.08 | 15.21 | 18.48 | 17.01 | 17.14 |
| 27 | Дш | 8 | 06.56 | 05.12 | 05.25 | 09.07 | 07.27 | 07.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.09 | 13.18 | 13.31 | 16.57 | 15.07 | 15.20 | 18.48 | 17.00 | 17.13 |
| 28 | Сш | 9 | 06.57 | 05.13 | 05.27 | 09.09 | 07.29 | 07.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.08 | 13.17 | 13.30 | 16.56 | 15.06 | 15.19 | 18.47 | 16.59 | 17.13 |
| 29 | Чш | 10 | 06.59 | 05.15 | 05.28 | 09.11 | 07.31 | 07.44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.07 | 13.16 | 13.29 | 16.55 | 15.05 | 15.18 | 18.46 | 16.59 | 17.12 |
| 30 | Пж | 11 | 07.00 | 05.16 | 05.29 | 09.12 | 07.32 | 07.46 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.06 | 13.16 | 13.28 | 16.55 | 15.04 | 15.17 | 18.46 | 16.58 | 17.11 |

*Алло, сездәниләр бар?*

# “Хажга бардым”



Әлхәмдү лилләһи, быел миңа да хаж кылу насыйп булды. Мина 27 яшь, Чаллы егете, хажга әни белән икәүләп бардык. Әлбәттә, тәэсирләр, эмоцияләр турында сүз белән генә әйтеп аңлату мөмкин түгел, барысын да үзең барып күрү кирәк. Кәгъбәтулланы, Мәккәне, Мәдинәне күрү – искиткеч тәэсирләр!



Сүз уңаеннан, хажга беренче тапкыр баручыларга шундый киңәш бирер идем: хаж алдыннан оештыручылар үткәргән дәресләргә даими йөреп, алдан ук кагыйдәләр белән яхшылап танышырга кирәк. Мин үзем дә “Ихлас” мәчете имамы Илназ хәзрәт дәресләренә йөрдем. Икенчедән, сәфәргә үзең белән артык йөк алырга кирәкми. Ике-өч футболка, башмак ише нәрсәләр дә җитә. Анда бик кызу, 45 градус астында егермешәр чакрым җәяү йөрергә туры килә. Безгә, яшьләргә, әллә ни авыр булмаса да, картрак кешеләргә җиңел димәс идем. Урамда бик эссе, ә кунакханәләрдә, автобусларда кондиционерлар эшли – температура кискен алышыну аркасында да өлкәннәргә бераз авыргарак туры килә.





Безнең кунакханә Әл-Хәрам мәчетеннән ерак түгел иде, аның матурлыгына, серлелегенә сокланып туймаслык!

**Фәрит Кубиев.**

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, яки башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**12 октябрь 16 сәг.**
**фактта 12 октябрь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**